ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 июнеь 2019ел № 2920

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу хакында нигезнамәне раслау турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә инвестиция активлыгын арттыру, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге мөлкәтеннән нәтиҗәле һәм рациональ файдалану максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 санлы карары белән расланган муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу хакында нигезнамәне кушымтада каралганча расларга.

2. 2008 елның 16 июлендә «Челнинские известия» газетасының 136-137 нче саннарында басылып чыккан Башкарма комитет Җитәкчесенең «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милке турында мәгълүмат бирү һәм тарату хакында» 2008 елның 27 июнендәге 1982 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карар имзаланган көннән башлап җиде көн эчендә аны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 7 июнендәге
2920 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу хакында
нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу турында нигезнамә (алга таба – нигезнамә) Россия Федерациясенең «Дәүләт сере турында» 1993 елның 21 июлендәге 5485-1 нче Законы, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне приватизацияләү турында» 2001 елның 21 декабрендәге № 178-ФЗ санлы Федераль законы, «Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр турында һәм мәгълүматны саклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә эшләнде һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милке (алга таба – муниципаль милек) турындагы мәгълүмат составын, шулай ук аны ачу ысулларын, тәртибен һәм срокларын билгели.

2. Муниципаль милек турындагы мәгълүматны ачу дигәндә юридик һәм физик затларның аннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү аңлашыла.

3. Муниципаль милекнең исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе (алга таба – җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе) тарафыннан бирелә. Соратып алына торган мәгълүматта дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булган очракта, мәгълүмат бирүдән баш тартыла.

4. Юридик һәм физик затлар мәнфәгатьләренә зыян китерә торган мәгълүматтан файдалану Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган җаваплылыкка китерә.

5. Муниципаль милек турындагы мәгълүмат Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милек реестрында (алга таба – Реестр) теркәлгән мәгълүматлар, шулай ук муниципаль милектәге җир участоклары турында белешмәләр күләмендә бирелә.

6. Муниципаль милек турындагы мәгълүматны ачу мәгълүмат тарату һәм юридик һәм физик затларга мәгълүмат бирү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Мәгълүматны тарату аны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (алга таба – шәһәрнең рәсми сайты) урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат бирү юридик һәм физик затларның язма мөрәҗәгатьләре буенча гамәлгә ашырыла.

## 2 бүлек. Муниципаль милек турында мәгълүмат тарату тәртибе һәм сроклары

7. Шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән таратыла торган муниципаль милек турындагы мәгълүмат түбәндәге мәгълүматлар исемлеге белән билгеләнә (мондый мәгълүматлар файдалану закон нигезендә чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган очраклардан тыш):

1) муниципаль учреждениеләр исемлеге (исеме, урнашу урыны);

2) муниципаль унитар предприятиеләр исемлеге (исеме, урнашу урыны);

3) устав капиталының өлеше (акцияләр пакетлары) муниципаль милектә булган хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге (хуҗалык җәмгыятенең исеме, урнашу урыны, устав капиталында муниципаль берәмлек өлеше);

4) муниципаль милектәге күчемсез милек (биналар, бүлмәләр) исемлеге (исеме, урнашу урыны, мәйданы, максатчан билгеләнеше, файдалануны чикләү, өченче затларның хокукларын йөкләү);

5) муниципаль милектәге күчемсез милек (җир участоклары) исемлеге (категориясе, кадастр номеры, урнашу урыны, мәйданы, максатчан билгеләнеше, файдалануны чикләү, өченче затларның хокукларын йөкләү);

6) муниципаль мөлкәтне приватизацияләүнең фараз планы (программасы);

7) муниципаль мөлкәтне приватизацияләүнең фараз планы (программасы) үтәлеше турында хисап.

8. Нигезнамәнең 5 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе тарафыннан квартал саен шәһәрнең рәсми сайтында кварталдан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча басылып чыгарга тиеш.

9. Приватизацияләүгә бәйле рәвештә муниципаль милектәге мөлкәт объектлары турында мәгълүматны ачу приватизацияләү турындагы законнар белән билгеләнгән күләмдә гамәлгә ашырыла.

## 3 бүлек. Муниципаль милек турында мәгълүмат бирү тәртибе һәм сроклары

10. Реестрда теркәлгән аерым мөлкәт объектлары (алга таба – исәпкә алу объектлары) турында мәгълүмат юридик һәм физик затларның мөрәҗәгате буенча хат яки Реестрдан өземтә рәвешендә бирелә.

Исәпкә алу объекты Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкенә караган очракта Реестрдан өземтә бирелә.

Мөлкәт объекты Реестрда булмаганда, мөлкәт объектының Реестрда булмавы турында хат бирелә.

Соратып алына торган мәгълүматта дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булганда, мәгълүмат бирүдән баш тарту турында хат бирелә.

11. Реестрдан өземтә (яки аны бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хат) мөрәҗәгать теркәлгән көннән башлап сигез эш көненнән дә артмаган срокта Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе тарафыннан бирелә.

12. Реестрдан өземтә түбәндәгеләргә бирелә:

1) исәпкә алу объектлары хокукына ия булучыларга һәм (яки) аларның законлы вәкилләренә;

2) исәпкә алу объекты хокукына ия булучылардан яки аның законлы вәкиленнән ышаныч язуы алган юридик һәм физик затларга;

3) Россия Федерациясе Хисап палатасына, Татарстан Республикасы Хисап палатасына;

4) җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясенең башка субъектларына;

5) федераль дәүләт хакимияте органнарына, шул исәптән:

- күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән килешүләр төзүне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнарга,

- салым органнарына,

- судларга, хокук саклау органнарына, исәпкә алу объектларына бәйле производство эшләренә мөнәсәбәтле суд приставларына-башкаручыларга һәм (яки) аларның хокукка ия булучыларына,

- федераль монополиягә каршы органга һәм аның Татарстан Республикасындагы территориаль органына.

13. Нигезнамәнең 12 пунктында күрсәтелмәгән затларга исәпкә алу объектларының Реестрда булуы турындагы мәгълүмат кына бирелә.

14. Язма рәвештә бирелүче, соратып алына торган мәгълүматны бирүдән баш тарту дәлилләнергә тиеш.

Соратып алына торган мәгълүматны бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәге сәбәпләр тора:

1) мөрәҗәгатьтә файдалану законнар нигезендә чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган белешмәләр соралу;

2) мөрәҗәгатьтә Реестрда мәгълүматлар булмаган мөлкәт объекты күрсәтелгән булу.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова